# ЭХ, СЕЗ МАТУР КЫЗЛАР

*Петр Кубашев көе*
*Николай Васильев шигыре (Удмуртчадан Риф Насыйбуллин тәрҗемәсе)*

Дус — ишләрем уйный-көлә,
Мин генә көлмим.
Уемның да ямен тапмыйм,
Ни булды, белмим.

*Кушымта:*
Эх, сез матур кызлар,
Ник шаяртасыз?
Йөрәгемнең януларын аңламыйсыз.

Мин эшемдә гел почетта
Һәрчак мактыйлар.
Кызлар гына урап уза,
Эх, яратмыйлар.

*Кушымта.*

Йөрәгемдә утлар яна,
Һич төшенмисез.
Арагыздан берегезне
Сөям өметсез.

*Кушымта.*

Нигә сезгә аңлашылмый
Минем хисләрем.
Шулай ук ялгыз үтәрме
Минем кичләрем?

*Кушымта.*